ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

## “Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында” Татарстан Республикасы Законының 12 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 13 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында” 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 12 статьяның 1 өлешендәге 3 пунктына “, Россия Федерациясе Хезмәт Геройлары” сүзләрен өстәргә;

2) 17 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Халыкка хокукый мәгълүмат җиткерү һәм аны хокукый гыйлемле итү югары белем бирү мәгариф оешмаларының юридик клиникалары һәм дәүләтнеке булмаган түләүсез юридик ярдәм үзәкләре тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2014 елның 28 феврале
№ 12-ТРЗ